| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2023 елның «01» марты Алабуга шәһәре № 239

2023 елда Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми мәсләкләре турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары белән Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарында һәм муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин.

2. Әлеге карарның 1 пункты Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.

3. Әлеге карарны «Яңа Кама» газетасында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук рәсми сайтта урнаштырырга: городелабуга.рф.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль берәмлек һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Р.М. Нуриев